# Хәерле көн





1



2



3



# “Артык сүзне тап!”

а) укы, укыйм,  эшлә,  йөгер

ә)  сөйли, кызыклы, шатлыклы,  көчле

б)  авыл, болын, күренми, елга

в)  шатлана, барма, күрмә, эшләмә

г)  баралар, бар, барсын,барсыннар



а)укыйм

ә) сөйли

б) күренми

в) шатлана

г) баралар



# Тема: Хәзерге заман хикәя фигыль



## МАКСАТ:

- тоташ сөйләмнән  хәзерге заман хикәя фигыльне таба белү;
- башка төр фигыльләрдән аера белү;
- аның төп грамматик билгеләрен ачыклау.



**Нәрсәне** белдерә?

**Нинди** сорауга җавап бирә?

**Нәрсәләр** белән төрләнә?

Җөмләдә **нәрсә** булып килә?



**Хәзерге заман хикәя фигыль сөйләүче сөйләп торган вакыттагы эш-хәлне, хәрәкәтне** белдерә.

**Нишли?** соравына җавап бирә?

**Барлыкта һәм юклыкта** була, **зат-сан** белән төрләнә.

Җөмләдә **хәбәр** булып килә.



**Төркемнәрдә эш.**

**1нче төркемгә.**

Нигезе тартыкка һәм - у – авазына тәмамланган фигыльләргә хәзерге заман хикәя фигыль кушымчаларын ялгап языгыз.

**Нәтиҗә чыгарыгыз.**

утырт - ку-

ярат – шу-

үс - ис -



**2 нче төркемгә.**

Нигезе сузык авазга тәмамланган  фигыльләрне хәзерге заманга куеп языгыз.

**Нәтиҗә чыгарыгыз.**

сакл**а** –　　　　ташы -

сөйл**ә** –　　　　балкы –

ба шл**а** -



**3 нче төркемгә.**

Нигезе -**й** һәм –**и** авазларына беткән фигыльләргә хәзерге заман хикәя фигыль кушымчаларын ялгап языгыз.

**Нәтиҗә чыгарыгыз.**

туй -
ки(й)–
җый -

ти(й)–
куй



## ***Көтелгән нәтиҗә:***

1. Нигезе тартыкка һәм **-у** авазына тәмамланган фигыльләргә хәзерге заманда **–а, -ә** кушымчасы ялгана.

утырт - **а**, ку - **а**

ярат – **а,** шу - **а**

үс - **ә,** ис - **ә**



2. Сузыкка беткән нигезләргә **–ый, -и** кушымчалары ялгана, соңгы сузык төшеп кала.

Соңгы авазы **ы** булса, аңа **–й** ялгана.

сакл**а –ый** ташы **-й**

сөйл**ә –и** балкы **–й**

башл**а** - **ый**



3. Нигезе -**й** һәм –**и** авазларына беткән

фигыльләргә дә **–а, -ә** кушымчасы ялгана.

Йа авазлары язуда –я хәрефе белән күрсәтелә.

Ту(**й**)–а - туя   ти(**й**)–ә - тия

Ки(**й**)–ә - кия

Җы(**й**)-а - җыя

Ку(**й**)– а - куя



**“Кем күбрәк әйтер?”**

Нокталар урынына хәзерге заман хикәя фигыльләр өстәп әйтегез.

1. Кош..........
2. Малайлар.........
3. Бала...........
4. Үсемлек........
5. Кызлар........
6. Агачлар.......



# Ял итеп алыйк

**1 нче бирем.**

Бирелгән җөмләләрдә хәзерге заман хикәя фигылен табып, юнәлешен билгеләгез.

1. *Кайчысыз киселә, җепсез тегелә.* (Табышмак)
2. *Яңа заман яңа байлыклар тудыра.* (Г. Бәширов)



**2 нче бирем.**

Шигырьне укыгыз һәм фигыльләрне хәзерге заман хикәя фигыль формасына куеп языгыз .

*Күзләремне ачты минем,*
*Иркәләде үз телем.*
*Үз телем яктыртты юлны,*
*Үз телем бирде белем.* ( М.Аитова)



**3 нче бирем.**

Шигырьне укыгыз һәм фигыльләрне хәзерге заман хикәя фигыль формасына куеп языгыз.

*Иң изге хисләремне мин,*

*Туган телдә аңлаттым.*

*Шуңа күрә туган телне*

*Хөрмәтләдем, яраттым.*

(Э.Мөэминова)



# 4 нче бирем.

Бирелгән фигыльләргә мәгънәдәш фигыльләр табып языгыз.

*йөгерә -*
*мактана –*
*ватыла -*



## 5 нче бирем.

Бирелгән фигыльләргә мәгънәдәш фигыльләр табып языгыз.

*елмая –*

*бөгелә –*

*саный -*



# Дәреслектә эш.     219 нчы күнегү


| Затлар | Берлек сан | Күплек сан |
|---|---|---|
| I зат | Көтәм, күзәтәм, тырышам. | |
| II зат | Төшәсең-төшәсең дә, китәсең, буласың. | |
| III зат | Кала, керә, килә, йомыла. | |



## ДӘРЕС БАШЫНДА КУЕЛГАН МАКСАТ:

- тоташ сөйләмнән хәзерге заман хикәя фигыльне таба белү;
- башка төр фигыльләрдән аера белү;
- аның төп грамматик билгеләрен ачыклау.




Хәзерге заман хикәя фигыль

- Алтын – көмеш яуган җирдән туган – үскән ил артык.
- Ватан белән ата – ананы чит җирдән таба алмассың.
- Туган илең – туган анаң, чит ил –үги ана.



**Өйгә эш.**

1. Дәреслектәге 221 нче күнегү (103 нче бит).
2. Әдәбият дәреслегеннән хәзерге заман хикәя фигыльләре кергән 5 җөмлә язып алырга.
3. Бирелгән бер мәкальнең мәгънәсен хәзерге заман хикәя фигыльләр кулланып аңлатырга.



# ҮЗБӘЯ

6 нчы сыйныф.  Исемем ___________________________

| | балл |
|---|---|
| Мин бу дәрестә актив катнаштым | |
| Биремнәрне үтәгәндә үземнән өлеш керттем | |
| Хәзерге заман хикәя фигыльләрнең грамматик билгеләрен ачыклый беләм (зат-сан, барлыкта һәм юклыкта, юнәлеш) | |
| Сөйләмем дөрес һәм тулы булды | |
| Хәзерге заман хикәя фигыльләрне сөйләмдә дөрес итеп куллана беләм | |



Иң югары  балл - “**5**” балл

Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

